**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ**

**КАРАРЫ**

**№ 2** **22.11.2019**

2020 елда Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Карамалы авыл җирлеге составына керүче,
Таллы-Бүләк авылында
үзара салым кертү турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Таллы - Бүләк авылында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2020 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге составына керүче Таллы-Бүләк авылында 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 2 группа инвалидларга 250 сум (50%) күләмендә бер тапкыр түләүне киметеп, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге оешмаларга юнәлдерергә:

- Таллы-Бүләк авылында урамнарны яктырту өчен яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, энергияне саклый торган лампалар урнаштыру, эшләр өчен түләү;
- Таллы-Бүләк авылындагы Лесная урамы буенча юлларга вак таш (щебенка) җәю (ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);

- Таллы  -Бүләк авылы зиратын койма белән әйләндереп алу өчен материал сатып алу;

- Таллы Бүләк авылында юлларны кардан чистарту.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга: Таллы-Бүләк авылы,  Үзәк урам, 8 нче йорт.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Карамалы авыл җирлеге Башлыгы А.Р. Ногманов

КАРАМАЛЫ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
КАРАМАЛИНСКИЙ СОВЕТ СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ